**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕГОРКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Егоркино ав. **КАРАР**

«14» сентябрь 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы «Егоркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгы
КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 25 сентябрендә 09 сәгать 00 минутка Үзәк урам, 33 номерлы йорт адресы буенча урнашкан Егоркино авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Садовая урамындагы 1-21, 2-24 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2023 елның 25 сентябрендә 10 сәгать 00 минутка Үзәк урам, 33 номерлы йорт адресы буенча урнашкан Егоркино авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Ленин урамы буенча 1-57, 2-16 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2023 елның 25 сентябрендә 11 сәгать 00 минутка Үзәк урам, 33 номерлы йорт адресы буенча урнашкан Егоркино авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Киров урамы буенча 1-31, 2-42 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә
4. 2023 елның 25 сентябрендә 13 сәгать 00тә Үзәк урам, 33 номерлы йорт адресы буенча урнашкан Егоркино авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегендә Совет урамы буенча 1-31, 10-16, Чапаев урамында 1Б-15, 2-16, Үзәк урамы буенча 37-57, 64-78 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. 2023 елның 25 сентябрендә 14 сәгать 00 минутка Үзәк урам, 33 номерлы йорт адресы буенча урнашкан Егоркино авылы мәдәният йорты бинасында

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авылында Ирек урамы буенча 2Б-40 йортларында, Беренче Май урамы буенча 2А-46.йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын уздыруны билгеләргә.

6. 2023 елның 25 сентябрендә 09 сәгать 00 минутта Егоркино авылы, Үзәк урам, 33нче йорт адресы буенча урнашкан Егоркино авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге Егоркино авылында 1-27, 2-64, Үзәк урамы; К.Маркс урамы буенча 1-45, 2-30; Ирек урамы буенча 1-9, 42-60; Беренче Май урамы буенча 1-17, 48-80 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча элек расланганнарга:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 11.10.2022 ел № 1 карары;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 11.10.2022 ел, № 2 карары үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын уздыруны билгеләргә

7. Халык җыенын үткәрү өчен Егоркино авылында яшәүчеләрнең исемлеген аеруга сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

8. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

9. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

Сез ризамы: "Егоркино авылының бюджет оешмалары территорияләрен коймалау" мәсьәләсен "Егоркино авылын су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару" мәсьәләсенә алыштырырга».

« РИЗА» «КАРШЫ».

10. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов